**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ VIII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 14**

Олы Чакмак авылы «3» март 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Олы Чакмак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмә хакында» Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 декабрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Олы Чакмак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмә хакында» Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 декаберендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 51 статьяны түбәндәгечә бәян итәргә:

«51 статья. Финанслауның иң чик күләмнәре

1. Финанс органы билгеләгән очракта һәм тәртиптә, чыгымнар буенча бюджетны үтәүне оештырганда, агымдагы финанс елының тиешле чорында акчалата йөкләмәләр өчен түләүнең иң чик күләмен (финанслауның иң чик күләмнәре) бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә һәм алучыларга раслау һәм җиткерү карала ала.

2. Финанслауның иң чик күләмнәре, тулаем алганда, бюджет акчаларын баш бүлүчегә, бүлүчегә һәм алучыга карата, бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә һәм алучыларга финанслау өчен гаризалар нигезендә, ай саен яки квартал саен, яисә агымдагы финанс елы башыннан арта бара торган нәтиҗә белән билгеләнә.»

1.2. 50 статьяның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет ассигнованиеләре исәбеннән үтәлергә тиешле акчалата йөкләмәләр өчен түләүне санкцияләү финанс органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»

1.3. 49 статьяның 2 пунктындагы 3 абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

«Җитәкчесе казна учреждениесенең бюджет сметасын раслау тәртибе нигезендә аны раслау хокукына ия булган бюджет сметасы күрсәткечләре, чыгымнар төрләре элементлары (төркемчәләре һәм элементлары) кодлары буенча бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, шулай ук бюджет йөкләмәләренең

җиткерелгән лимитлары чикләрендә дәүләт идарәсе секторының операцияләр классификациясенең тиешле төркемнәренең (маддәләренең) статьялары (күчермәләре) кодлары буенча өстәмә рәвештә детальләштерелергә мөмкин.»

1.4. 48 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) чыгымнар төрләре төркемчәләре (төркемчәләре һәм элементлары) буенча расланучы бюджет йөкләмәләре лимитларын детальләштерүне гамәлгә ашыру хокукын яисә бурычын билгеләргә мөмкин.»

1.5. 48 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

«Бюджет йөкләмәләре чыгымнары һәм лимитлары буенча бюджет язмасы күрсәткечләре, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 190 һәм 191 статьяларында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башына кадәр ведомство карамагындагы бюджет акчаларын алучылар һәм бүлүчеләргә җиткерелә.»

1.6. 46 статьяның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-артык түләнгән яки артык алынган салым, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын кире кайтару (зачет, төгәлләштерү) өчен кирәкле артык бүленгән суммаларны, акчаларны, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентлар суммасын һәм артык түләттерелгән суммаларга исәпләнгән процентлар суммасын Федераль казначылык тарафыннан керемнәрне исәпкә алу һәм аларны Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында бүлү өчен билгеләнгән тиешле бюджетларның бердәм счетларына, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күчерү»;

1.7. 46 статьяның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон (карар) һәм Татарстан Республикасының башка законнары һәм РФ Бюджет кодексы нигезләмәләре нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән агымдагы финанс елында гамәлдә булган нормативлар буенча бүленә торган Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм башка керемнәр бүлүдән бюджетка керүләрне һәм башка кертемнәрне исәпкә алу һәм бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларыннан Россия Федерациясе бюджет системасына күчерү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Мөслим муниципаль районы**

**Олы Чакмак авыл җирлеге Башлыгы** **И.М.Габидуллин**